Рушания Алтай

татар дөньясы
3 апрель 2024 18:23

# Төрек галиме Польша студентларына татарлар турында лекцияләр укыган



Фото: Фатих Экиҗи

Төрек галиме **Фатих Экиҗи** Польшаның Адам Мицкевич исемендәге университеты студентларына татар халкы һәм аның теле, тарихы турында лекцияләр укыган. Бу хакта галим үзе хәбәр итә.

Ул европалы студентларны Идел буе татарлары, Татарстан тарихы һәм татар халкының бүгенге көне белән таныштыра. Татар теленең тарихи чорлары, хәзерге торышы һәм милләтнең характеристик үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирә. Татар мәдәниятенең алгы пландагы элементлары турында сөйли, бүгенге татар алфавитын өйрәтә һәм башлангыч дәрәҗәдә татар теле дәресләре бирә.

Фатих Экиҗи Польшаның Познань шәһәрендә урнашкан әлеге университетта бер атна лекцияләр укый, аңа бу мөмкинлек «Эразмус» халыкара студент һәм галимнәр алмашу программасы кысаларында бирелә.

Фатих Экиҗи - Төркиянең Ататөрек исемендәге университет галиме, кандидатлык диссертациясен «Татар язучысы

Галимҗан Гыйльманның повестьларына анализ» темасына яклый, әдипнең әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итеп «Һәҗәөйку» исемле әдәби журналда бастыра.

Кызыклы яңалыкларны күзәтеп бару өчен Телеграм-каналга язылыгыз

#татар

---

**җәмгыять**
3 апрель 2024 18:15

# КФУ метеорологы Татарстанда карның кайчан эреп бетәчәген әйтте




Фото: © «Татар-информ»

Россия Гидрометеорология үзәге фаразлары буенча, Казанда апрель аенда уртача температура нормадан бер-ике градуска югары булачак. Алдагы декадада һава температурасы нормадан дүрт градуска югары була. Бу хакта «Татар-информ»га КФУ профессоры, география фәннәре докторы **Юрий Переведенцев** сөйләде.

«Уртача тәүлеклек температураның биш градустан күчеше гадәттә апрель уртасында була, ә апрель ахыры – май башында 10 градустан күчә, ә 15 градустан күчү еш кына майның 25ләренә туры килә. Климатик нормалар буенча тотрыклы кар катламы 12 апрель тирәләрендә эри», – диде ул.

КФУ галиме фикеренчә, апрель җылы булса да, карның гадәти вакытка эреп бетүе икеле. Чөнки кар запасы күп.

«Кар актив эри. Туфрактагы туң артык тирән түгел, әмма быел кар бик күп», – диде Юрий Переведенцев.

Кызыклы яңалыкларны күзәтеп бару өчен Телеграм-каналга язылыгыз